СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 358 от 18.05.2020

на № __от ________

# КАРАР

Авыл җирлегенең мөлкәте белән эш итү вәкаләтләрен тапшыру һәм муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында авыл җирлекләре мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2020 елның 21 гыйнварындагы “Милеккә сатылган яисә sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгыннан файдаланып арендага бирелгән муниципаль мөлкәт олеше” индикаторын үтәү мәсьәләсе буенча киңәшмә беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Арташ, Олы Кибәче, Олы Нырты, Олы Шыңар, Югары Симет, Явлаштау, Эзмә, Иштуган, Килдебәк, Курсабаш, Мишә, Мичән, Түбән Шытсу, Сатыш, Иске Икшермә, Тимершык, Шекше, Шәмәрдән, Юлбат авыл җирлекләре Советларына һәм Саба шәһәр җирлеге Советына Саба муниципаль районы Җир һәм молкәт монәсәбәтләре палатасына түбәндәге вәкаләтләрне тапшыруны тәкъдим итәргә:

– авыл җирлегенең мөлкәте белән эш итү вәкаләтләре;

– муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында авыл җирлекләре мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча вәкаләтләр.

2. Саба муниципаль районы составына керүче Арташ, Олы Кибәче, Олы Нырты, Олы Шыңар, Югары Симет, Явлаштау, Эзмә, Иштуган, Килдебәк, Курсабаш, Мишә, Мичән, Түбән Шытсу, Сатыш, Иске Икшермә, Тимершык, Шекше, Шәмәрдән, Юлбат авыл җирлекләре Советлары һәм Саба шәһәр җирлеге Советы тарафыннан әлеге карарныц 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәр кабул ителгән очракта:

2.1. Саба муниципаль районының Молкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл (шәһәр) җирлекләре Башкарма комитетлары белән килешүләр төзергә;

2.2. Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына, әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, бюджет законнары нигезендә, “2020 елга һәм 2021 - 2022 елларныц планлы чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты турында “2019 елның 17 декабрендәге 326 номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында”гы карар проектын эшләргә һәм карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасыныц Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районыныц http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарныц үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе А.М. Галиуллинга йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы                                        Р.Н. Минниханов